| | | |
|---|---|---|
| **ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.01.2023 Балык Бистәсе штп. №11пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкы өчен 2023 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорда торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен, социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын наем шартнамәләре буенча тоту өчен түләү, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен, гомуми җыелышта торак биналарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларда торак милекчеләре өчен торак биналарны карап тоту өчен түләү күләмен раслау турында” гы 29.12.2022 №401пи карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 154, 156, 158 статьялары , Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт өчен кертемнең минималь күләмен билгеләү турында» 29.06.2013 №450 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәреш кертү хакында» 30.12.2022 ел, №1484 карары нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 29.12.2022 №401пи карары белән расланган (12.01.2023 №02пи үзгәрешләре белән) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкы өчен 2023 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге чорда торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) күләмен, социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарын наем

шартнамәләре буенча тоту өчен түләү, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен, гомуми җыелышта торак биналарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортларда торак милекчеләре өчен торак биналарны карап тоту өчен түләү күләменә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

"01.01.2023 елдан электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау" юлында "0,29 " саннарын "1,22" саннарына алыштырырга;

"01.07.2023 елдан электр белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау" юлында "0,30" саннарын "1,27" саннарына алыштырырга;

"01.07.2023 елдан газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау" юлында "1,22 " саннарын "0,29"саннарына алыштырырга;

"01.07.2023 елдан газ белән тәэмин итү челтәрләрен агымдагы ремонтлау" юлында "1,27" саннарын "0,30" саннарына алыштырырга;

"Торак бинаны ремонтлау һәм территорияне төзекләндерү" юлында "һәм территорияне төзекләндерү" сүзләрен төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Л. Исланов